ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 ел, 30 октябрь Петровский Завод авылы №6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мостафин авылы гражданнары җыенын медпункт бинасында 2020 елның 11 ноябренә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Петровский Завод авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 250 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Мостафин авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру.;
- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүченең эш хакы, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Мостафин авылында чишмэ тозеклэндере, төзелеш материаллары сатып алу;
- Мостафин авылынын Октябрьская урамын ремонтлау очен таш сатып алу

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru),

хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә игълан итәргә.

Петровский Завод
авыл җирлеге башлыгы: А.Б. Хөснетдинов